**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 21 октябрь № 789

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 5 март, 74 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 18 июнь, 246 нчы; 2009 ел, 19 гыйнвар, 24 нче; 2010 ел, 27 июль, 591 нче; 2012 ел, 2 февраль, 78 нче; 2013 ел, 31 август, 622 нче; 2014 ел, 23 декабрь, 1006 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

коллегия составына Гуськов Евгений Александровичны, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисен (килешү буенча) кертергә (килешү буенча).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче, 2014 ел, 30 август, 630 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлекнең 5.7 пунктындагы беренче абзацка «,Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисен.» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\789.docx